*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№5 (27)

Март-апрель, 2018 нче ел

## КОЛЛЕКТИВ ТУРЫНДА САНЛЫ АҢЛАТМА

| | |
|---|---|
| *«ТР физик тәрбия һәм спорт отличнигы» күкрәк билгесе* | *1* |
| *ТР ның «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе* | *8* |
| *РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы* | *5* |
| *ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Почет грамотасы* | *16* |
| *“Мәгариф” өстенлекле проекты җиңүчеләре* | *5* |
| *ТР 2010-2015 нче елларда мәгариф стратегиясен тормышка ашыручы “Иң яхшы укытучы” гранты ияләре* | *16* |
| *2016-2017 нче елларда ТР укытучыларының һөнәри үсеш гранты ияләре* | *6* |
| *Югары квалификацион категорияле укытучылар* | *16* |
| *Беренче квалификацион категорияле укытучылар* | *21* |

## ГИМНАЗИЯ - БЕЛЕМ, ИҖАТ, СПОРТ ТЕРРИТОРИЯСЕ




“Мөслим гимназиясе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе – Мөслим районы мәктәпләре арасында үз йөзе, үз статусы булган уку йорты. Менә 15 ел инде без беренче сыйныф укучыларын үз стеналарыбызда кабул итеп, алардан белемле, тормышка яраклашкан шәхесләр тәрбияләп чыгарабыз. Гимназия коллективын эрудицияле, компетентлы белгеч Азат Фәрит улы Мирзаянов җитәкли. Татарстан Республикасы электрон белем бирү системасында компетенция үзәге буларак, гимназия укытуда инновацион технологияләрне кулланышка кертүдә алдынгы тәҗрибә тарату базасы булып тора. Яңалыкка омтылучан педагоглар, укучы эшчәнлеген оештыруның отышлы формаларын кулланып, укыту-тәрбия юнәлешендә күркәм нәтиҗәләргә ирешәләр. Гимназия “Гомуми белем бирү программасының планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешү шарты буларак уку һәм дәрестән тыш эшчәнлекне интеграцияләү” темасы астында эшли.

Сәләтле укытучы гына балаларның сәләтен үстерә ала дигән гыйбарә яши. Педагоглар һөнәри осталык бәйгеләрендә бик теләп катнашалар, профессиональ осталыкларын үстерәләр, республика, регионара чараларда үз тәҗрибәләрен тараталар. Гимназия укытучылары арасында “Ел укытучысы”, “Сыйныф җитәкчесе” республика бәйгесе, “Мастер-класс” бөтенроссия конкурсы, “Авыл укытучысы” республика конкурсы җиңүчеләре, төрле Грант ияләре бар. “ФГОС таләпләреннән чыгып, укыту һәм дәрестән тыш эшчәнлекне интеграцияләү аша педагогларның һөнәри осталыгын күтәрү” дигән методик проблема өстендә эшлибез. Укытучыларыбыз барлык сәләтләрен, методик осталыкларын, күңел җылысын балаларга биреп эшлиләр. Гимназия – профессионаллар территориясе.

Гимназия – бердәм эшләүче тупланган коллектив. Башлангычтан алып, югары сыйныфларга кадәр эзлеклелек, дәвамчанлык саклана. Башлангыч сыйныф укытучылары: Мортазина Л.Г., Мирзасалихова Г.Ш., Латыпова И.В., Фәхертдинова Л.Ә., Исмәгыйлова Г.Ф., Ермолаева Э.С., Рәхмәтуллина А.Р., Гомәрова А.Р., Әюпова Г.Ә. Федераль стандартларны этаплап тормышка ашырып киләләр. Югары сыйныфларда фән ияләре укучыларга сыйфатлы белем бирү өчен нәтиҗәле хезмәт куялар. 100 дән артык укучының муниципаль олимпиадаларда җиңүче һәм призер булуы, республика олимпиадаларында, бөтенроссия, халыкара олимпиадаларында нәтиҗәләребез булу һәм ОГЭ, ЕГЭ күрсәткечләренең югары булуы – бердәм хезмәт нәтиҗәсе.

Гимназия ике ел рәттән “Тулы көн мәктәбе” муниципаль проектын тормышка ашыру юнәлешендә эшли. Укучылар күп төрле түгәрәкләргә, спорт секцияләренә тартылган. Хореография, шахмат, “Арт-дизайн”, “Робототехника” түгәрәкләре, “Маска”, “Балкыш” сәхнә осталыгы түгәрәкләре, “Музыка дөньясында” сәнгать студиясе, ике телдә “ТЫЛСЫМ+” һәм “КЛЮЧ” газеталары проектлары дәвамлы проектлар буларак тормышка ашырыла. Укучыларыбыз “Йолдызлык” республика, “Яшь бөреләр” район фестивале, “Илһам”, “Ак җилкән” яшь язучылар бәйгеләре җиңүчеләре, “Көмеш кыңгырау” балалар гәҗитенең даими хәбәрчеләре.

Спорт буенча уңышларыбыз шактый. Ике ел рәттән гимназия укучылары командасы Анапа шәһәрендә узган “Президент ярышлары”нда катнашып, яхшы нәтиҗәләргә иреште. Гимназия укучылары Сафиуллин Ринат, Гәрәев Илназ милли көрәш һәм билбау көрәше буенча республика, Россия командасы составында ярышларда катнашты. Укучылар баскетбол, волейбол, мини-футбол, җиңел атлетика, милли көрәш, билбау көрәше, армрестлинг, чаңгы, хоккей буенча яхшы күрсәткечләргә ирешеп киләләр.

Коллектив бердәм булганда, бернинди авырлыклар да киртә була алмый. Бердәмлектә – көч.

***Миннегалиева Л.Р., укыту эшләре буенча директор урынбасары***


# ГИМНАЗИЯ – СЫЙФАТЛЫ БЕЛЕМ ГАРАНТЫ

Гаяз Исхакыйның 140 еллыгына багышлап Чистай шәһәрендә уздырылган фәнни-практик конференциядә 10б сыйныфы укучылары Сабитова Айгөл һәм Зиязова Миләүшә “Г.Исхакыйның “Тормышмы бу?” һәм И.Гончаровның “Обломов” әсәрләрендә уртак мотивлар” темасына фәнни эзләнү эшен тәкъдим иттеләр һәм 1 урын яуладылар. Фәнни җитәкчеләре - Тимергалиева Э.В.



11а сыйныфы укучысы Шамукаева Эльвина татар теленнән республика олимпиадасы җиңүчесе буларак, халыкара олимпиадада катнашу хокукы алды. Америка, Канада, Финляндия, Польша, Япониядә, Россиянең барлык төбәкләрендә яшәүче татарлар белән аралашып, ике турда сынаулар үтеп, Эльвина 3 нче дәрәҗә Лауреат исеменә лаек булды.









V республикакүләм “Фоат Садриев укулары” гимназия укучылары өчен шактый уңышлы булды. Китапханәче Солтанова Г.М. укытучылар секциясе эшендә катнашып, өченче урын яулады.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мирзаморатова Г.М. һәм инглиз теле укытучысы Бакирова Г.Р. җитәкчелегендә 7б сыйныфы укучысы Нассер Мәрьям 1 нче урынга, Әхмәтҗанова Алинә 2 нче урынга лаек булды.

9а сыйныфы укучысы Сәфәргалина Ильвина 2 урын яулады. Фәнни җитәкчесе - Авзалова З.З.

НГПУ галимнәре биология буенча уздырган региональ олимпиадада Кадыйрова Айзилә (11б) 1 нче урын, Фәхертдинова Айгөл (10б), Хатипова Миләүшә (11б), Ханнанова Алинә (9б) 2 нче урын, Зиязова Миләүшә (10б), Шарифуллина Фәридә (9а) 3 нче урын алдылар. Аларны биология укытучысы Л.Ф.Бариева әзерләде.

“Елабужский Парнас” региональ иҗади конференциясендә 2а сыйныфы укучысы Харитонов Данил 3 нче дәрәҗә дипломга лаек булды. Укытучысы: Гомәрова А.Р.





7б сыйныфы укучысы Бариев Илһам математика буенча туган як турында мәсьәләләр төзү остасы икәнлеген исбат итә алды. Ул “Казан – математик мәсьәләләрдә” республикакүләм конференциясендә чыгыш ясап, 2 нче урынга лаек булды. Аның хезмәте “Казан – математик мәсьәләләрдә” җыентыгына кертелде. Укытучысы: Заялова Л.Н.

Математика укытучыларының районкүләм олимпиадасында ике ел рәттән гимназиянең математика укытучысы Заялова Л.Н. җиңү яулады. Котлыйбыз!




Зәй шәһәрендә уздырылган “Тукай укулары” региональ конференциясендә катнашып, 10а сыйныфы укучысы Булат Әхмәтҗанов призер булды. Фәнни җитәкчесе – рус теле һәм әдәбияты укытучысы Хәйруллина Ч.А.

6б сыйныф укучысы Солтанова Алия шагыйрь һәм прозаик Рафаил Газиз исемендәге төбәкара әдәби бәйгедә 1 нче урынны алды (Җитәкчесе - Солтанова Г.М.)







“Яшь тикшеренүчеләр - 2018” республикакүләм фәнни-эзләнү эшләре һәм проектлары конкурсы нәтиҗәләре буенча Бәдретдинова Адилә (5а), Хәйруллина Алина (3а) призер булдылар. Укучыларны башлангыч сыйныф укытучысы Мортазина Л.Г., тарих укытучысы Бәдретдинова Н.Н. әзерләде.

## ГИМНАЗИЯ – ТӘРБИЯ УЧАГЫ

“Тормыш дәресләре” район проекты кысаларында гимназиядә күп төрле тәрбияви чаралар оештырыла. Аларда районыбызның күркәм кешеләре, хезмәт алдынгылары, сугыш ветераннары, җитәкчеләр, яшьләр лидерлары, юрист, экономист, агроном, ветеринарлар, гомумән, кызыклы шәхесләр катнаша.

Бала чактан алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас.
*Р.Фәхреддин*

Мөслим үзәк китапханәсендә оештырылган "Йолдызга сорау” циклыннан артистлар, сәнгать әһелләре белән очрашуларга теләп йөрибез.

Әфганстан сугышы герое Маис абый Шәрипов белән очрашу күңелләрне тетрәндерерлек мизгелләре белән истә калды.

Тирә-ягыбыздагы өлкәннәргә игътибарлы булу – тәрбиялелек билгесе. Караучысыз калган картларга, ятимнәргә шефлык ярдәме оештырабыз. Кыш көне кар көрибез, яз көне бакча, ихата җыештыру эшләрендә булышабыз.

Врачлар, медицина хезмәткәрләре гимназиябездә еш булалар. Төрле авырулар турында сөйләп, профилактик чаралар уздырала.

Гимназиядә полиция, МЧС хезмәткәрләре дә еш була. Куркынычсыз яшәешебез турында кайгыртучанлык күрсәтеп, төрле хәлләрдә үзеңне ничек тотарга, югалып калмаска мөмкин булуы турында сөйлиләр.














## ГИМНАЗИЯ – ТАЛАНТЛАР МӘЙДАНЧЫГЫ

Март-апрель айларында сәләтле укучылар өчен “Созвездие-Йолдызлык” республика иҗат фестивале, “Яшь бөреләр” район фестивале старт алды. Гимназия укучылары әлеге бәйгеләрдә бик теләп катнашалар. Югары категорияле музыка укытучысы Гөлнур Әзһәм кызы Фәхретдинова җитәкчелегендә “Сәйлән” кызлар вокаль ансамбле уңышлы чыгыш ясады. 1 нче дәрәҗә лауреат булдылар. Гимназиянең вокаль ансамбле 2 нче урынга лаек дип табылды.

Бурганова Карина (2а), Нургалиева Лилиана (2а) “Конферансье” номинациясендә, Сәгъдиева Айгөлгә (2а) “Вокал-соло” номинациясендә тиңнәр булмады. Әюпова Илнара дипломант булды. Укытучылары - Гомәрова А.Р.










## ПРОЕКТ ЭШЛӘРЕ – ФГОС ТАЛӘБЕ

Апрель аенда барлык ФГОС классларында ел буена башкарган проект эшчәнлегенә нәтиҗә ясалды. 2-3, 6-8 нче сыйныфлар эшләрен тәгәлләп, комиссия каршында хисап тотты. Укучылар проект эшләренә бик җаваплы караганнар. Башлангыч сыйныфлар эшне күбрәк укытучы җитәкчелегендә һәм ата-аналар ярдәме белән башкарсалар, калган сыйныфларда мөстәкыйльлек сизелә. 6 нчы а сыйныфы укучыларының проектлары аеруча отышлы булды. Алар география, биологиядән эксперимент, татар әдәбияты һәм рус әдәбияты буенча интеграль проектлар тәкъдим иттеләр. 7 нче сыйныфлар эшкә иҗади якын килгәннәр. Алар музыка, рәсем сәнгате, инглиз теле, география һәм физкультура буенча бик җитди эшләгәннәр. Мондый эшчәнлек төре укыту-тәрбия процессында бик зур әһәмияткә ия. Проект белән шөгыльләнү метапредмет нәтиҗәлелеккә ирешүдә бер адым буларак бәяләнә. 4-5 нче сыйныф укучыларының проект эшләрен яклау алдагы атнада планлаштырыла.








## ГИМНАЗИЯ – СПОРТ ТЕРРИТОРИЯСЕ



“Куркынычсыз хәрәкәт” – “Безопасное колесо” конкурсында 5 нче б сыйныф укучылары уңышлы чыгыш ясады. Безнең гимназия командасы 3 нче урын яулады, шәхси беренчелектә дә уңышлар бар. Гәрәйханов Рөстәм (5б) – велосипед йөртү остасы һәм юл йөрү кагыйдәләрен иң яхшы белүче буларак 2 нче урыннар, Ахунова Рәзилә (5б) – медицина ярдәме күрсәтү буенча 3 нче урын алды. Команда җитәкчесе – педагог-оештыручы Башаров И.И.

Гимназия укучылары баскетбол, волейбол, мини-футбол, җиңел атлетика, милли көрәш, билбау көрәше, армрестлинг, чаңгы, хоккей буенча яхшы күрсәткечләргә ирешеп киләләр.





# ЭКОЛОГИЯ һӘМ БЕЗ

“ЭКОЛОГИЯ ЕЛЫ” кысаларында шактый эшләр башкардык. Кыш көне агачларга җимлекләр ясап, кошларны сыйладык. Яз җитүгә, агач башларына сыерчык оялары ясап элдек. Гимназия территориясен чистарту өмәләрендә катнашабыз. “Чиста Мөслим”, “Яшел Мөслим”, “Үз агачыңны утырт” акцияләреннән читтә калмыйбыз. “Кояшлы Ык” территориясендәге өмәләрдә катнашырга исәплибез.

Чистарту икеайлыгы кысаларында өмәләр дәвам итә. Һәрберебез чисталык, матур яшәешебез хакына үз өлешебезне кертик! Үзебез яшәгән микрорайон, гимназия территорияләре, парк-скверларыбыз балкып торсын!

Укучыларның региональ фәнни-экологик конференциясендә Фәхертдинова Айгөл (10б) – җиңүче булды, Бариева Илина (5б) – 1 нче дәрәҗә диплом, Бадретдинова Адилә (5а) - 2 нче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. Укучыларның фәнни җитәкчеләре – биология укытучысы Бариева Л.Ф., химия укытучысы Семенова В.Г.





## Ут чәчәк




Борын-борын заманда яшәгән, ди, киң болында кып-кызыл матур чәчәк. Аны тирә-яктагы чәчәкләр, үләннәр “Ут чәчәк” дип атаганнар, ди. Чөнки ул төнлә дә хайваннарга юл күрсәтеп янып утырган. Ут чәчәк иртән иртүк кояш белән уянып, таң чыклары белән юына икән. Аның матурлыгына тирә-яктагы үсемлекләр таң калган, хәтта хайваннар да аның яныннан узганда читләп кенә, басмаска тырышып узалар икән, ди. Менә бервакыт көчле җил чыккан, җирдә яткан кәгазь, полиэтиленнар оча башлаган, шул вакытта кара төстәге полиэтилин очып килгән дә Ут чәчәккә киелеп калган. Ут чәчәк ярдәм сорап, алга, артка борылган, кычкырып та караган, ләкин аны берәү дә күрмәгән, ишетмәгән. Сулыш алырга авыр була башлаган, һава җитмәгән. Ут чәчәк әкренләп сула, шиңә башлаган, бик тә талчыккан, җылы шифалы яңгыр суларының тавышын гына ишетеп торган Ут чәчәк. Шулай итеп, Ут чәчәк сыгылып төшкән һәм үсүдән дә туктаган. Аның урынында кара җир генә калган, ди.

Менә дусларым, кешеләрнең мәрхәмәтсезлеге, тәртипсезлеге аркасында кешеләр үзләре генә түгел, үсемлекләр, хайваннар да интегә икән. Ял итәргә кырга, урманнарга баргач, әниләрегезгә, әтиләрегезгә, иптәшләрегезгә әйтегез: полиэтилен капчыкларны, капрон шешәләрне, консерв савытларын, сок савытларын ташламасыннар. Аларны махсус чүп савытларына салыгыз!

**Шуны онытмыйк: “Табигатьне саклыйк - үзебезне яклыйк!”**

***Зарипова Азалия, 2 нче б сыйныфы укучысы***

## Сыерчыклар килде



Туган ягыма ямьле яз килде. Кояшлы көнне тагы да ямьләп, җылы яклардан сыерчыклар кайтты. Алар бер оядан икенчесенә күченеп үзләренә оя сайлый башладылар. Ә без ояларны инде ясап куйган идек. Чөнки беләбез: бу - безнең изге бурычыбыз. Мәктәбебездә дә, һәрьелдагыча, сыерчык ояларына бәйге игълан иттеләр. Укучылар берсеннән-берсе матур оялар ясап алып килделәр. Аннары әтиләр белән бергә аларны агачларга элеп тә куйдылар. Бу тырыш укучыларга рәхмәт хатлары тапшырылды. Язның яме булган сыерчыкларга без шундый бүләк ясадык. Сыерчыкларның сөенә-сөенә ояга чыбык-чабык ташулары, кечкенә кошчыкларын шунда үстерүләрен күзәтеп торуы үзе ни тора!

***Кошларга ярдәм итү, аларны яклау һәм саклау - безнең изге бурычыбыз!***

***Хисамова Язилә,
3 нче а сыйныфы укучысы***

## Табигать баласы

Без табигать балалары,
Табигатьне сөябез.
Матур гөлләр үстерәбез
Көндә сулар сибәбез.
Җәйләр җитсә, табигатькә
Ял итәргә чыгабыз.
Артыбыздан чүп калдырмый,
Җыештырып китәбез.

***Гатауллина Ильвина,
2 нче б сыйныфы укучысы***

## Җәй көнендә

Әй рәхәт, җәй көнендә
Ык буенда коену.
Яр буенда талларының
Куенына сыену.
Шушы матур гүзәллекне,
Дуслар, бергәләп саклыйк,
Табигатьнең һәр кешегә
Көч биргәнен онытмыйк.

***Зарипова Азалия,
2 нче б сыйныфы укучысы***

## Яз җитте

Менә матур яз җитте,
Карлар да эреп бетте.
Гөрләп ага ташулар
Басулрдан, таулардан.
Озакламас җитәр җәй
Эссе һәм кызу чаклар,
Ә хәзергә әле яз
Күкләр булсын гел аяз!

***Хаҗиев Алмаз,
3 нче б сыйныфы укучысы***

## Яз

Менә ямьле яз җитте.
Салкын кыш үтеп китте.
Ыкта бозлар эреде,
Карлар да эреп бетте.
Сыерчыклар да кайтты -
Дөньялар матурланды!

***Газетдинова Адилә,
Газетдинова Азалия,
3 нче б сыйныфы
укучылары***

## Яз

Менә тагын яз килде,
Елмаеп кояш көлде.
Таулар ачылды кардан,
Елгалар чыкты ярдан.

Көньяктан кайтты кошлар -
Безнең канатлы дуслар.
Оя да корыр алар,
Үстерерләр балалар.

Йокысыннан уянып,
Аю да чыгар өскә.
Табигать матурланып
Керер ямь-яшел төскә.

***Аглиуллина Гөлзирә,
2 нче б сыйныфы
укучысы***




## Яз

Яз килгәнгә сөенеп,
Бер тавык “кыт-кыт” килә:
“Без язга чыктык, - ди, -
Йомырка салдым мин,
Син дә сал, чыпчык, - ди.
Кошлар кайта сагынышып
Туган-үскән җирләрен.
Килсеннәр әйдә, килсеннәр,
Без көткәнне белсеннәр,
Ояларны күрсеннәр,
Бүләк диеп белсеннәр!

***Габидуллина Азалия,
3 нче б сыйныфы
укучысы***

# ТУКАЙ - БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛЛӘРДӘ








## Шүрәленең дәвамы…



Сезгә көлке, һич авыртмый бармагыгыз,
Явыз егет кысты аны, аңламыйсыз.
Төшенделәр эшнең асылына шүрәлеләр,
Хәзер инде берсе көлми, шүрләделәр.
Уйладылар: әгәр батыр егет тагын килсә,
Һәм рәнҗетсә безне берәм-берәм, җәлләмичә,
Һич ярамый бу урманда озак тору,
Тиз арада кирәк булыр моннан таю.
Егет уе бу урманда хуҗа булу,
Безнең ише урман сарыкларын куу.
Озын-озак юлга бик тиз җыендылар,
Шүркә, Шүрәлинә, башка шүрәлеләр.
Шул көннән соң инде башка очрамады,
Һичбер затка мондый җен-пәриләр.

*Дәүләтшин Әмир,*
*3 нче б сыйныфы укучысы*

## 3 нче б сыйныфы, 3 нче в сыйныфы укучыларының иҗат җимешләре (укытучылары Фәхертдинова Л.Ә., Рәхмәтуллина А.Р.)










## ЯШЬ КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР МӘЙДАНЫ



***Әюпова Илнара, 2 нче а сыйныфы укучысы***

### СЕРЛЕ КҮЛМӘК

Тегеп кидек матур күлмәк,
Әйтерсең лә - гөлчәчәк.
Шул чәчәкнең эчләрендә
Үзем нәни күбәләк.

Күбәләктәй уйныйм әле,
Гөлдән-гөлгә куныйм әле.
Тирә-юньгә нурлар сибеп,
Бар җиһанны кочыйм әле.

### ТАТАР КЫЗЫ

Танышырга телим дуслар
Бик тә кыю булганга
Шаян татар кызы булам
Мөслимдәме туганга.

Исемем матур – Илнара,
Әниемнеке – Илмира,
Абыемныкы – Риназ –
Ул сөйләшә бик тә аз.

Ә мин менә тел бете,
Шигырьләр бик яратам:
Дусларыма, туганнарыма
Үземнән нур таратам.

Кирәк икән - тыпырдатып
Татар биюен биим.
Кирәк икән – дисбе тартам,
Дога, мөнәҗәт укыйм.

Җәй көнендә урманнарда
Җыямын гел ак чәчәк.
Чәчәкләрдәй балачагым,
Матур минем киләчәк!

Озын сүзнең кыскасы-
Мин кызларның остасы.
Бар яклап та уңганы,
Кыю, чибәр, булганы!

### БӘХЕТ АГАЧЫ

Бәхет агачы ясадык
Әнием белән бергә.
Тәңкә саен теләкләр
Теләдек һәммәбез дә.

Иң кирәге – сәламәтлек,
Сәламәт булсын һәркем.
Авырмыйм, чирләмим,-дип
Зарядка ясыйм һәр көн.

Әйтерсең лә, чын агач,
Исем китте ясагач.
Яфраклары да чын бәрхет,
Теләп торсын ул безгә бәхет.

## БАКА КЫЗЫ БАКУКУ



Борын заманнарда түгел, безнең көннәрдә, бик матур камышлы күлдә яшәгән, ди, бака кызы Бакуку. Ул җырчы булырга хыялланган, ди. Көн дә таң беленү белән, хыялын тормышка ашырырга теләп, җыр суза икән: “Бак-бак, бака-ка, бака-ка-а”.

Тик Бакукуның тавышы бик ямьсез, җырлавы бигрәк тә моңсу икән. Күл буенда бөтен бөҗәкләр, кош-кортлар шул шыксыз тавышны ишетмәс өчен, төрлесе төрле якка качышып бетәләр икән.

Шулай да, бер көнне Ала карга Бакукуның җырын тыңлап торган да, бакага әйткән: “Үзең бик гүзәл, ләкин җырлавыңның бер рәте юк, моңың да юк, күл буендагы җан ияләрен бик тынгысызлыйсың. Бик ерак түгел, көнбатышта, ун-унбиш чакрымлап ераклыкта, бик матур түгәрәк күл бар, менә анда бакалар бик моңлы итеп җырлыйлар икән. Син шунда бар әле, бәлки сиңа да моң серләрен өйрәтерләр”.

Бакуку әнисеннән рөхсәт алган да, кояш чыкканчы ук юлга кузгалган. Болыннар, кырлар, басулар буйлап сикереп бара торгач, ниһаять, ул барып җиткән.

Чынлап та, монда бакалар берсеннән-берсе матуррак җырлыйлар икән. Бака кызы Бакуку телсез калып, моң дөньясына чумган. Араларыннан бер бака Бакукуны күреп алган да, сүз каткан: “Гүзәл бака, безнең якларда ни йомыш белән йөрисең?” - дигән.

Бака кызы барысын да сөйләп биргән. Алар Бакукуның җырчы булырга хыялlануын хуплаганнар, аңа моң серләрен өйрәтә башлаганнар. Бер ай дигәндә, Бакуку моңлы итеп җырлый башлаган, ди. Үзенә ярдәм иткән түгәрәк күлдәге бакаларга рәхмәт әйтеп, кайтыр юлга кузгалган.

Туган ягына, үзенең камышлы күленә кайткач, көн дә концерт куйган. Хәзер инде аның моңын тыңларга төрле яклардан бөҗәкләр, кош-кортлар агыла икән. Исләре китеп тыңлаганнар.

Менә шулай, дусларым. Сезнең дә хыялларыгыз булса, аны тормышка ашырырга тырышыгыз. Тырышкан табар - ташка кадак кадар.

***Гамиров Алмаз, 2 нче а сыйныфы укучысы***

## ГИМНАЗИЯ – БЕЛЕМ УЧАГЫ

***Хөрмәтле әти-әниләр, кадерле укучылар!***

*Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге булган Мөслим гимназиясе яңа 2018-2019 нчы уку елына 1 нче сыйныфка укучылар кабул итә.*

*Гаризаларны дәүләт муниципаль хезмәт күрсәтү порталында (USLUGI.TATARSTAN.RU) бирергә мөмкин.*

**БЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФКА КАБУЛ ИТҮЧЕ УКЫТУЧЫЛАР**



**Мирзасалихова Гөлназ Шәйдулла кызы, югары квалификацион категорияле укытучы**



**Ермолаева Эльвира Сабирҗан кызы, беренче квалификацион категорияле укытучы**

***Гимназиягә кабул ителүче 6-7 яшьлек балаларның интеллектуаль үсешенә таләпләр:***

- гади логик мәсьәләләр чишә белү;
- төркемдәге артык предметларны таба, җитмәгәнен исте алу;
- предмет, вакыйгаларның урнашу чылбырын билгели алу;
- вакыйга эзлеклелегенә төшенү;
- предметның охшаш, аермалы якларын табу;
- табышмак, гади ребусларны чишә белү.
- Чит җирдә, ят кешеләр алдында үзенең белгәнен сөйләп күрсәтә алырлык кыюлык хуплана.



***Мирзаянов Азат Фәрит улы - Мөслим гимназиясе директоры:***

*XXI гасыр – инновацияләр гасыры. Укучыларның белем дәрәҗәсе заман белән бергә атларга тиеш. «Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге» буларак, гимназиядә укыту-тәрбия процессы югары информацион технологияләргә таянып оештырыла. Барлык укытучыларның һөнәри, педагогик-психологик, методик, информацион-коммуникатив яктан компетентлы булуы мине куандыра.*

*Киләчәктә Мөслим гимназиясе республикада гомуми белем бирүче инновацион уку йортлары арасында лаеклы үз урынын табар, дип ышанам.*

***Күзаллау дәрәҗәсенә таләпләр:***

- үз исем-фамилиясен, әтиәнисе, аларның эш урыннары турында белү;
- хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын, бөҗәкләр һәм балыкларны, йорт һәм кыргый хайваннарын, яшелчә һәм җиләк-җимешне, агач һәм куакларны тану, аеру;
- календарьда айларның урнашу тәртибен, ел фасылларын, атна-көннәрен билгели, күрсәтә белү;
- сәгатьне таный белү;
- төрле табигать күренешләре турында төшенчә булу;
- төсләрне атый, аларны аера белү;
- популяр спорт төрләрен белү;
- җәяүлеләр өчен юл йөрү кагыйдәләре белән таныш булу, төгәл үтәү.

## ГИМНАЗИЯ БҮГЕН



БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Россия “Милли мәгариф” проекты җиңүчесе – 2008.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Укучыларның туклануын оештыру буенча иң яхшы мәктәп ашханәсе” республикакүләм конкурсы җиңүчесе - 2009.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Сәламәтлек саклау юнәлешендә “Алтын дәрәҗә”ле мәктәп” квалификацион характеристикасына ия булган уку йорты - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – медицина кабинетларының Республика смотр-конкурсы җиңүчесе - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – РТ ның «Иң яхшы авыл мәктәбе», ә РФнең «Чыгарылыш сыйныф укучылары югары нәтиҗәләр бирүче иң яхшы мәктәп», 2017

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – 474 укучы, 47 укытучы бердәм эшләүче коллектив.

**ТЫЛСЫМ+**
Март-апрель, 2018 нче ел
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина, Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Салихова Динара, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Тираж:** 100